| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 декабря 2024 ел № 291

**«2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2023 елның 14 декабрендәге 223 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәгә таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. «2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2023 елның 14 декабрендәге 223 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2024 елга Балтач муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 1 499 999,87 мең сум итеп;

2) Балтач муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 1 556 813,41 мең сум итеп;

3) Балтач муниципаль районы бюджеты кытлыгын 56 813,54 мең сум итеп».

1.2. Карарның 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балтач муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны түбәндәгечә исәпкә алырга:

- әлеге карарның 15 нче кушымтасы нигезендә 2024 елда 1 011 514,00 мең сум итеп;

- әлеге карарның 16 нче кушымтасы нигезендә 2025 елда 891 203,37 мең сум һәм 2026 елда 865 697,40 мең сум итеп.»

1.3. Карарның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балтач муниципаль районы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2024 елга 30 002,94 мең сум, 2025 елга 20 530,70 мең

сум, 2026 елга 21 163,10 мең сум итеп расларга һәм аларны тиешенчә 2024, 2025 һәм 2026 елларда Балтач муниципаль районының гомуми файдалану юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә.».

1.4. Әлеге карарның 1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче, 5 нче, 6 нчы, кушымталары нигезендә «2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына Балтач муниципаль районы бюджеты турында» 2023 елның 14 декабрендәге 223 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарының 1 нче, 3 нче, 5нче, 7 нче, 15 нче, 17 нче кушымталарын яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 октябереннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе

Р.Р.Нотфуллин